**СОВЕТ ДАЧНОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. Дачное, ул. Центральная, 11 помещ.1

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДАЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дачный авылы, Үзәк ур., 11, 1б.

Тел./факс: +7(84365) 78-3-33, e-mail: Dach.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**14.09.2023 г.** **№ 7**

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 7 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 321-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен салым салуның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачное авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ**:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге Советы карарына (2018 елның 15 маендагы 89 номерлы, 2018 елның 15 августындагы 96 номерлы, 2018 елның 27 декабрендәге 116 номерлы, 30.11.2022 № 55 номерлы Советы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 1 пунктчасының дүртенче абзацында «, бирелгән» сүзен һәм «, дача» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктның 1 пунктчасында өченче абзацны төшереп калдырырга;

3.1 пунктында өченче абзацны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру юлы белән: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А.М. Давлетшин